ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» июня 2025 ел № 593

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлешенең 28 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен расларга.

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү өчен рекреацион зоналар булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 2016 елның 12 декабрендәге 1285 номерлы (2025 елның 10 мартындагы 197 номерлы үзгәрешләр белән) карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.М. Гатиятовка йөкләргә.

Җитәкче А.Г.Хисаметдинов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты
Карарына
17.06.2025 ел, № 593
Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләре**

## Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр Россия Федерациясенең 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Су кодексы (2023 елның 25 декабрендәге редакциясендә), башка федераль законнар нигезендә су объектларыннан рекреацион максатларда (туризм, физик культура һәм спорт, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту, шул исәптән балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру) файдалануны билгели.

1.2. Кагыйдәләрдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

- Акватория – табигый, ясалма яисә шартлы чикләр чикләрендәге су пространствосы;
- су хуҗалыгы – су объектларын өйрәнү, алардан файдалану, саклау, шулай ук суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аннан килгән зыяннарны бетерү буенча икътисадый һәм башка эшчәнлек төрләре:
- су ресурслары – су объектларындагы һәм файдаланыла яисә файдаланылырга мөмкин булган җир өстендәге һәм җир асты сулары;
- су объекты – табигый яисә ясалма сулык, су агымы яисә башка төрле суларның даими яисә вакытлыча тупланышы су режимына хас формаларга һәм билгеләргә ия булган объект;
- су режимы – су объектында су дәрәҗәсенең, чыгымының һәм күләменең вакыт буенча үзгәрүе;
- су фонды – Россия Федерациясе территориясе чикләрендәге су объектлары җыелмасы;
- судан файдаланучы – су объектыннан файдалану хокукы бирелгән физик зат яисә юридик зат;
- су хуҗалыгы системасы – су объектлары комплексы һәм су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү һәм аларны саклау өчен билгеләнгән гидротехник корылмалар комплексы;
- су төбе балчыгы – су объектларының төбен тирәнәйткән, гидротехник эшләр башкарган, су объектларында урнашкан гидротехник һәм башка

корылмаларны, ясалма утрауларны, җайланмаларны төзегән, төзекләндергән, файдаланган, Россия Федерациясенең эчке су юлларын төзегән һәм карап торткан вакытлара, суларның тискәре йогынтысын булдырмаганда һәм аннан килгән зыяннарны бетергәндә һәм федераль законнар белән билгеләнгән башка очракларда алынган су объектлары төбендәге балчык;

- дренаж сулары - су объектларына агызу өчен дренаж корылмалары бүлеп бирә торган сулар;

- су объектларыннан файдалану (судан файдалану) – Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең, физик затларның, юридик затларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен су объектларыннан төрле ысуллар белән файдалану;

- суларның тискәре йогынтысы – су объектлары ярларын су басу яисә җимерү;

- су объектларын саклау – су объектларын саклауга һәм торгызуга юнәлдерелгән чаралар системасы;

- агып төшүче сулар – яңгыр, кар, инфильтрация, сиптерү-юу, дренаж сулары, үзәкләштерелгән су агызу системасының агып төшүче сулары һәм су объектларына алардан файдаланганнан соң агызыла торган яисә су җыю мәйданыннан агып чыга торган башка сулар;

- су объектының рекреация зонасы – ул халыкның күпләп ял итүе һәм су коену өчен файдаланыла торган су объекты яисә аның ярлары янәшәсендәге участогы.

## 2. Рекреация максатларында файдалану өчен билгеләнгән су объектларын яисә аларның өлешләрен билгеләүгә таләпләр

2.1. Рекреация максатларында файдалану өчен билгеләнгән су объектлары яисә аларның өлешләре гамәлдәге кануннар нигезендә билгеләнә.

2.2. Су объектының рекреация зонасының яр буе территориясе санитария һәм янгынга каршы нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

Су объектларының рекреация зоналары агып төшүче сулар агып чыга торган урыннардан агым буенча кимендә 500 метрдан югарырак, порт гидротехник корылмаларыннан, пристаньнардан, причаллардан, нефть салу җайланмаларыннан 250 метрдан да якынрак һәм 1000 метрдан да түбәнрәк урнашмый.

Су коену өчен билгеләнгән һәм агым уңаеннан 500 метрга кадәр югарырак урыннарда кер юу һәм хайваннар коену тыела.

Агым сулык янындагы су көзгесе мәйданы бер су коенучыга кимендә 5 кв.м, ә агым булмаган сулыкта 10 - 15 кв. м. туры киергә тиеш. Һәр кешегә кимендә 2 кв. м пляж мәйданы туры килергә тиеш.

Коену өчен билгеләнгән урыннарда балчыклы сулар, су әйләнеше, чокырлар һәм секундына 0,5 метрдан арткан агым чыгарылмаска тиеш. Су коену урыннарында йөзү чикләре бер-берсеннән 25-30 метр һәм 1,3 метр тирәнлектәге урыннардан 25 метрга кадәр ераклыкта урнашкан кызгылт-сары төстәге

буйкалар белән билгеләнә.

Участокның төбе акрынлап ике метр тирәнлеккә кадәр авыш булырга, анда чокырлар, киртәләр булмаска тиеш, ул суүсемнәрдән, тамырлардан, ташлардан, пыяладан һәм башка әйберләрдән азат булырга тиеш.

Пляж билгеләнгән санитария таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Су коену сезоны башланыр алдыннан сулык төбе йөзү чигенә кадәр водолазлар тарафыннан тикшерелергә һәм су үсемлекләреннән, агач тамырларыннан, ташлардан, пыяладан һ. б. чистартылырга, акрынлап тау итәге 1,75 метр тирәнлеккә кадәр, ә полосаның ярдан киңлеге 15 метрдан да ким булмаска тиеш.

2.3. Су объектларының рекреация зоналары әлеге кагыйдәләрдән алынган стендлар, суда бәхетсезлек очракларын кисәтү материаллары, су һәм һава температурасы турындагы мәгълүматлар белән җиһазландырыла, кояштан саклану өчен җитәрлек күләмдә ятаклар, чатырлар, зонтлар белән тәэмин ителә.

2.4. Су объектларының рекреация зоналарында су коену сезоны чорында суда зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина персоналы кизү торырга мөмкин.

Су объектының рекреация зоналары, кагыйдә буларак, радиофикацияләнгән булырга, телефон элемтәсе булырга һәм шәһәр транспорты белән тәэмин ителергә тиеш.

Су янында массакүләм ял итү урыннарында спиртлы эчемлекләр сату катгый тыела.

2.5. Тыела:

- кисәтү һәм тыю язулары булган щитлар (аншлаглар) куелган урыннарда су коенырга;

- Җиһазландырылмаган, таныш булмаган урыннарда су коенырга;

- Йөзү чикләрен билгеләүче буйкалар артына йөзәргә;

Моторлы, җилкәнле суднолар, җилкәнле көймәләр һәм башка йөзү чаралары янына йөзеп килергә;

Катерлардан, көймәләрдән, причаллардан, шулай ук бу максат өчен яраклаштырылмаган корылмалардан суга сикерергә;

- Сулыкларны пычратырга һәм чүпләргә;

Спиртлы эчемлекләр эчәргә, исерек хәлдә су коенырга;

- Үзең белән этләр һәм башка хайваннар алып килергә;

- Яр буенда, гардеробларда һәм чишенү бүлмәләрендә кәгазь, пыяла һәм башка чүп-чар калдырырга;

- Туп белән бу максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда спорт уеннары уйнарга, шулай ук суда суга чуму һәм су коенучыларны эләктереп алу белән бәйле шаяртуларга юл куярга;

Ялган тревога кычкырырга;

- Такталарда, бүрәнәләрдә, ятакларда, автомобиль камераларында, кабартылган матрацларда йөзәргә;

- Йөзәргә өйрәткәндә куркынычсызлык өчен укыту яисә күнегүләр үткәрүче укытучы (инструктор, тренер, тәрбияче) җаваплы була;

- Йөзәргә өйрәтү махсус билгеләнгән урыннарда үткәрелергә тиеш;

- Һәр граждан суда бәла-каза кичерүчегә хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тиеш.

Радиотрансляция җайланмалары, стендлар, кисәтү материаллары белән тутырылган фотовитриннар ярдәмендә суда бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча системалы рәвештә аңлату эшләре алып барылырга тиеш.

2.6. Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе вәкилләренең су объектларының рекреация зоналары, ял базалары һәм йөзү бассейннары администрациясе өчен суда йминлек чаралары күрү өлешендә күрсәтмәләрен үтәү мәҗбүри.

## 3. Ял итү зоналарын һәм башка территорияләрне, су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән рекреация максатларында файдалануга бәйле пляжларны да кертеп, билгеләүгә таләпләр.

3.1. Халыкның массакүләм ял итү урыннарына (зоналарына) шәһәрләрнең генпланнарында, районның планлаштыру һәм шәһәр яны зонасын үстерү схемаларында, җирле үзидарә органнары карарларында курорт зоналарын оештыру, шифаханәләр, ял йортлары, пансионатлар, туризм базалары, дача һәм бакча-яшелчә кишәрлекләре урнаштыру, халыкның ялын оештыру урыннары (шәһәр пляжлары, парклар, спорт базалары һәм аларның ачык һавадагы корылмалары) керә.

Массакүләм ял итү урыны (алга таба – ял итү урыны) булып гамәлдәге законнар нигезендә бүленгән, рекреация максатларында интенсив файдалану өчен тиешенчә җиһазландырылган, шулай ук әлеге кишәрлектә урнашкан һәм ял итү урыны объектлары һәм җиһазлары сыйфатында функциональ йөкләнешкә ия булган, әлеге участокта урнашкан һәм территорияне төзекләндерү объектларына һәм элементларына, шулай ук кече архитектура формаларына караган объектлар һәм ял итү урыннары йөкләнешен үз эченә алган җәмәгать киңлеге, яшелләндерелгән территория тора.

Ял итү урыннары су объектын яисә аның су коену, спорт-савыктыру чаралары һәм башка рекреацион максатлар өчен файдаланыла торган яисә каралган өлешен үз эченә алрга мөмкин.

3.3. Яңа ял урыннары булдыру турында карар Арча муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре тарафыннан генераль план, җирдән файдалану һәм территориядә төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә кабул ителә.

3.4. Рекреация зонасын эчә торган су белән тәэмин иткәндә аның “ГОСТ Р Россия Федерациясенең дәүләт стандарты. Эчәргә яраклы су. Сыйфатны контрольдә тотуны оештыруга һәм методларга гомуми таләпләр".

Душ җайланмаларын урнаштырганда аларда эчәргә яраклы су бирелергә тиеш (ГОСТ 17.1.5.02-80 п.2.7).

Бәдрәфләр ясаганда чистарту корылмаларына агып төшүче суларны агызып, канализация үткәрү каралырга тиеш. Канализация булмаганда, су үткәрми торган өемнәр ясарга кирәк.

Пляжларны төзегәндә – пляжда медицина пункты һәм күзәтү каланчасы булган коткару станциясе бинасы каралырга тиеш.

3.5. Чүп контейнерлары керү юллары уңайлы бетон мәйданчыкларда урнаштырылырга тиеш. Чүп-чарны көн саен чыгарырга кирәк.

3.6. Рекреация зонасы янында шәхси һәм җәмәгать транспортының ачык автостоянкалары урнаштыру каралырга тиеш.

30 автомашинага кадәр сыйдырышлы ачык автостоянкалар рекреация зонасы чикләреннән кимендә 50 м, 100 автомашинага кадәр сыйдырышлы – кимендә 100 м, 100 автомашинага кадәр сыйдырышлы – кимендә 200 м ераклыкта урнаштырылырга тиеш.

Рекреация зонасыннан ачык автостоянкаларга кадәр санитар-саклау өзеклекләре яшелләндерелергә тиеш.

**Су коену сезонын ачу һәм ябу срокларына таләпләр.**

Җәйге чор башлану белән, көндез һава температурасы 18 градустан югары күтәрелгәндә һәм су объектларының рекреация зонасында суның уңайлы температурасы билгеләнгәндә, Арча муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең норматив-хокукый актлары белән коену сезонын ачу һәм ябу сроклары билгеләнә.

**Рекреация максатларында су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән файдалануга бәйле чаралар үткәрү тәртибе.**

“Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы (п. п. 1, 3) таләпләре нигезендә:
эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү максатларында, шулай ук дәвалау, сәламәтләндерү һәм рекреация максатларында кулланыла торган су объектлары, шул исәптән шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләрендә урнашкан су объектлары (алга таба – су объектлары) кешегә зарарлы йогынты ясаучы биологик, химик һәм физик факторлар чыганагы булмаска тиеш.

Су объектларының кеше өчен куркынычсызлыгы һәм (яки) зарарсызлыгы критерийлары, шул исәптән суда химик, биологик матдәләрнең, микроорганизмнарның рөхсәт ителә торган иң чик концентрациясе, радиация фоны дәрәҗәсе санитария кагыйдәләре белән билгеләнә.

5.2. Су объектыннан конкрет күрсәтелгән максатларда файдалану су объектының санитария кагыйдәләренә һәм су объектыннан халык сәламәтлеге өчен куркынычсыз файдалану шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик нәтиҗә булганда рөхсәт ителә.

5.3. Су объектларын саклау, аларның пычрануын һәм чүпләнүен булдырмау өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыручы органнар белән килештерелгән су объектларына зарарлы йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары, су объектларына химик, биологик матдәләр һәм микроорганизмнар агызуның иң чик мөмкин нормативлары билгеләнә.

5.4. Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары,

җирле үзидарә органнары, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар, әгәр су объектлары халык сәламәтлеге өчен куркыныч тудырса, аларның вәкаләтләре нигезендә күрсәтелгән су объектларыннан файдалануны чикләү, туктатып тору яисә тыю буенча чаралар күрергә тиеш.

5.5. 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясының 1.1 пункты нигезендә су объектлары акваториясеннән рекреация максатларында, шул исәптән пляждан файдалану өчен, су объектының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдаланучылар һәм хокук ияләре гамәлгә ашыра ала.

5.6. Рекреацион максатларда су объектларының яр буйларыннан файдаланучы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә су объектының санитария кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик нәтиҗә алуны тәэмин итәргә кирәк. Санитар-эпидемиологик нәтиҗәнең гамәлдә булу вакыты җәйге сезонга билгеләнә.

Су объектын рекреацион максатларда файдалануга санитар-эпидемиологик нәтиҗә алу өчен мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор Идарәсенең (Татарстан) Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарындагы территориаль бүлегенә “Татарстан Республикасының гигиена һәм эпидемиология үзәге” федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе яки башка аккредитацияләнгән оешма тарафыннан үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре буенча гариза һәм рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган су объектының су сыйфатын лаборатор тикшерүләр нәтиҗәләре һәм пляж территориясендәге туфракның (комның) сыйфаты турында эксперт нәтиҗәсен тапшырырга кирәк.

Арча муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренә ел саен билгеләнгән рекреация зоналарында “пляж сезоны” оештырырга, судан куллану килешүләре әзерләргә һәм төзергә кирәк, алар нигезендә Россия Федерациясе Су кодексының 11 статьясындагы 2 өлешенең 1 яисә 3 пунктлары, 15, 47, 49 һәм 50 статьялары нигезендә федераль милектәге, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге яисә муниципаль берәмлекләр милке (алга таба – су объекты) су объектлары яисә аларның өлешләре дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм гомуми файдаланудагы су объектының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең хокук ияләре тарафыннан пляжлардан файдалану өчен су объектлары акваториясеннән файдалану максатларында файдалануга бирелә.

## . Су коену зоналарын һәм рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка зоналарны билгеләүгә таләпләр.

Ял итү урыннары ял итү зоналарында Россия Федерациясенең җир, су, урман һәм шәһәр төзелеше кодекслары нигезендә булдырыла.

Ял итү урыннарына ял итү зоналары, бозга чыгу урыннары, пляжлар, су коену урыннары, суда спорт объектлары, сәламәтләндерү һәм профилактика процедураларын кабул итү объектлары һәм корылмалары керә. Территориядә һәм акваториядә файдаланыла торган ял итү урыннары инфраструктурасы

объектлары, җиһазлар һәм эшләнмәләр тиешле техник регламентлар, милли стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмалары таләпләрен канәгатьләндерергә тиеш. Ял итү урыннарында күрсәтелә торган хезмәтләр милли стандартлар таләпләренә туры килергә тиеш. Ял итү урыннарына квалификацияле персонал хезмәт күрсәтергә тиеш. Һәр ял итү урыны өчен җаваплы эксплуатант билгеләнә. Ял итү урыннарында эш режимнары, файдалану кагыйдәләре һәм таләпләре, шулай ук су-коткару станцияләренең һәм постларының составы, дислокациясе һәм җаваплылык зонасы билгеләнә. Ял итү урыннары бер яки берничә җир кишәрлегендә һәм су объектлары акваторияләрендә төзелергә мөмкин. Территорияләр һәм су объектлары җитәрлек рекреация сыйдырышлылыгына ия булырга тиеш. Исәп-хисапларны махсуслаштырылган оешмалар үткәрә. Ял итү урыннарында аларның торышын әлеге стандарт таләпләренә туры килүгә мониторинг үткәрәләр. Су объектыннан яисә аның кишәрлегеннән рекреацион максатларда файдаланучы су объектын саклау, аны пычранудан, чүпләнүдән һәм ярлыланудан кисәтү чараларын, шулай ук күрсәтелгән күренешләрнең зыяннарын бетерү чараларын Су кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырырга тиеш.

## Су объектларын саклауга таләпләр.

7.1. Су объектлары милекчеләре су объектларын саклау, аларның пычрануын, суларның чүпләнүен һәм саегуын булдырмау чараларын, шулай ук күрсәтелгән күренешләрнең нәтиҗәләрен бетерү чараларын гамәлгә ашыралар. Федераль милектәге, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге, муниципаль берәмлекләр милкендәге су объектларын саклау Россия Федерациясе Су кодексының 24 - 27 статьялары нигезендә дәүләт хакимиятенең башкарма органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7.2. Муниципаль берәмлекләр милкендәге су объектларына карата җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мондый су объектларына ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү;

2) суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аннан килгән зыяннарны бетерү чараларын гамәлгә ашыру;

3) мондый су объектларын саклау чараларын гамәлгә ашыру:

4) мондый су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкаларын, бу түләүне исәпләү һәм алу тәртибен билгеләү.

## Рекреация максатларында су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән файдалану һәм аларны саклау өчен кирәкле башка таләпләр.

Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм гомуми файдаланудагы су объектының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең хокук ияләре тарафыннан пляжлардан файдалану өчен, шулай ук үз эшчәнлекләрен федераль законнар нигезндә гамәлгә ашыручы физкультура-

спорт оешмалары, балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары, туроператорлар яисә турагентлар тарафыннан рекреация максатларында кирәкле су объектлары акваториясеннән файдалану өчен, ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның, инвалидларның оешкан ялын гамәлгә ашыру өчен су объектлары акваториясеннән файдалану аукцион үткәрмичә төзелә торган судан файдалану шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.2. Биналарны, корылмаларны рекреацион максатларда архитектур-төзелеш проектлаштыру, төзү, төзекләндерү, файдалану башлау һәм файдалану, шул исәптән пляжларны төзекләндерү өчен, корылмалар су законнары һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.3. Рекреацион максатларда (туризм, физик культура һәм спорт, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту, шул исәптән балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру) файдаланыла торган территорияләрдә су саклау зоналарының чикләрен һәм су объектларының яр буе саклау полосаларының чикләрен билгеләү, җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре ярдәмендә билгеләүне дә кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

8.4. Су объектларыннан файдаланганда физик затлар, юридик затлар әлеге кодекс һәм башка федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган җир өсте су объектларын саклау кагыйдәләре һәм җир асты су объектларын саклау кагыйдәләре нигезендә су хуҗалыгы чараларын гамәлгә ашырырга тиеш.